Кузнечиха авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ – КАРАР

24.10.2022 № 25-4

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кузнечиха авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 14 декабря 24-1 номерлы карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кузнечиха авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кузнечиха авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 14 декабря 24-1 номерлы карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2.1 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Формалаштырылган гарызнамәнең формаль-логик тикшерүе гариза бирүченең һәр кырын электрон формадагы кырны тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон формадагы электрон кыр ачыкланганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән сорауның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кузнечиха Башлыгы
авыл җирлеге

Р.Р. Ибраһимов